**Татар теленнән эш программасына аннотация**

4 нче сыйныф өчен татар теле фәненнән эш программасы Дәүләт стандартының Федераль компонентына нигезләнгән башлангыч мәктәпләрнең татар теле фәненнән үрнәк программасына нигезләнеп төзелде:

Татар теленнән тематик план Татарстан Республикасы Мәгариф министрлыгы тарафыннан рөхсәт ителгән дәреслек (“Перспективалы башлангыч мәктәбе” И.Х.Мияссарова, К.Ф Фәйзрахманова) нигезендә төзелде .

Татар теле укытуның **максаты:**

белемнәрне системага салу, тирәнәйтү, яңа мәгълүмат бирү, укучыларда әйтмә һәм язма сөйләмнәрен үстерү.

**4 нче сыйныф укучыларының белем дәрәҗәләрендә булачак нәтиҗәләр:**

-сүзнең мәгънәле кисәкләрен, тамыр һәм кушымча, ясагыч һәм төрләндергеч кушымчаларны аера һәм аларны сүзне кулланганда файдалана белү;
-тамырдаш сүзләрне икеләнүсез аеру;
-сүзләрнең төзелешен модель итеп күрсәтә белү, модель үрнәгендә яңа сүзләр ясау;
-сүз төркемнәре: исем, сыйфат, фигыль алмашлык, кисәкчә, бәйлекләр;
-җөмләнең баш кисәге, ия, хәбәр;
-җөмләнең иярчен кисәкләре;
-сузык һәм тартык авазларны, калын һәм нечкә сузыкларны икеләнүсез аеру, анализ ясау, бирелгән теориягә таянып, аларга анализ ясау,бирелгән аваз схемасына,характеристика тиешле авазлар, сүзләр сайлау;
-сүзләрне иҗекләргә бүлү һәи иҗекләп юлдан-юлга күчерү;
-өйрәнгән орфограммалар кергән 75 -80 сүзле текстны, җөмлә ахырында тиешле тыныш билгеләрен куеп, диктант итеп язу, текстларны хатасыз һәм каллиграфик дөрес итеп күчереп язу;
-сүз төркемнәрен һәм аларның грамматик билгеләрен тану, аеру (исемнең – санын, тартым кушымчалары булганда – затын, килешен, фигыльнең заманын, затын, санын);
- -сүзгә фонетик анализ ясау, иҗекләргә бүлү,авазларны сүздәге тәртиптә ачык, дөрес әйтеп атап чыгу;
-үзең язганны бирелгән үрнәк белән чагыштыру;
-җөмләне анализлау: әйтү максаты, интонация буенча төре, баш һәм иярчен кисәкләр;
-әзер яки бергәләп төзелгән план буенча 85- 90 сүзле тексны изложение итеп язу, текстның темасын һәм фикерен чагылдыра алу, кызыл юлны саклау;
сөйләгәндә һәм язганда, текст өлешләре, җөмләләр арасында бәйләнеш булдыру;
хикәяләү, тасфирлама, фикер йуртү тибындагы текстларны аера, төзи белү һәм кечкенә күләмле текстлар язып кую;